ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.11.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2204**

2019 елның 12 мартындагы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 623 номерлы карарындагы 3 нче кушымтага өстәмәләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 4 пункты нигезендә һәм 2020 елның 05 сентябреннән Зеленодольск муниципаль районы муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре хезмәтләренә тарифларны (бәяләрне) карау буенча комиссия карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы өстәмә белем бирүнең муниципаль бюджет учреждениеләре күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 12 мартындагы 623 номерлы карарына 3 нче кушымтаны (2019 елның 23 июлендәге 1508 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге эчтәлекле 15.1 пункт белән тулыландырырга:

| | **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Үлчәү берәм.** | **Бәясе,сум.** |
|---|---|---|---|
| 15.1 | «Семицветик» иҗат студиясендә индивидуаль дәресләр | 1 шөгыль өчен | 350 |

2 Әлеге карарны ЗМР Советы аппаратының массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге начальнигы Р.З. Хаҗиевка «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев